КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь

г.Казань

№ 1749

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында» 2008 ел, 22 октябрь, 763 нче карары белән расланган 2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында» 2008 ел, 22 октябрь, 763 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 сентябрь, 711 нче; 2023 ел, 11 февраль, 135 нче; 2023 ел, 3 апрель, 392 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерга якын килү нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлектә:

«Татарстан Республикасы энергосистемасының конкурентлык сәләтен үстерү буенча төп юнәлешләр» бүлекчәсендә:

бишенче абзацка «, кеше гомеренә, сәламәтлегенә» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «әйләнә-тирә мохиткә,» сүзләреннән соң «кеше гомеренә, сәламәтлегенә,» сүзләрен өстәргә;

«Нефть чыгару» дигән 6.1.2.2 бүлекчәнең җиденче абзацында «комплексның әйләнә-тирә табигать мохитенә» сүзләреннән соң «, кеше гомеренә, сәламәтлегенә»

сүзләрен өстәргә;

«Транспорт комплексы үсешенең төп концептуаль нигезләмәләре» бүлекчәсенең дүртенче абзацында «транспортның әйләнә-тирә мохиткә» сүзләреннән соң «, кеше гомеренә, сәламәтлегенә» сүзләрен өстәргә;

«Җирле телефон элемтәсе» бүлекчәсенең алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

«Продукциянең иң мөһим төрләрен җитештерү» бүлекчәсендә:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадның өстенлекле юнәлешләрендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен банклар кредитларын җәлеп итүче предприятиеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2001 ел, 24 апрель, 228 нче һәм «Татарстан Республикасы предприятиеләренең инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан кызыксындыру чаралары турында» 2003 ел, 28 гыйнвар, 53 нче карарлары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

унсигезенче абзацта «Мәсәлән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 9 июнендәге 357 номерлы карарында машиналарның һәм җиһазларның аерым төрләренә карата читтән кертелә торган таможня пошлиналары ставкаларын бары 9 айга раслый» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 бүлектә:

«Табигать ресурслары» бүлекчәсенең илленче абзацында «әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкка тискәре йогынты» сүзләрен «әйләнә-тирә мохиткә, кеше гомеренә, сәламәтлегенә тискәре йогынты» сүзләренә алмаштырырга;

«Озак сроклы перспективада әйләнә-тирә мохитне саклау максатлары һәм төп бурычлары» бүлекчәсендә:

бишенче абзацта «әйләнә-тирә мохиткә» сүзләреннән соң «, кеше гомеренә, сәламәтлегенә» сүзләрен өстәргә;

уникенче абзацта «экологик һәм социаль-гигиена мониторингы» сүзләрен «атмосфера һавасының дәүләт экология мониторингы» сүзләренә алмаштырырга;

«Сәнәгатьне экологик яктан имин үстерү» бүлекчәсенең беренче абзацында «зарарлы» сүзен «тискәре» сүзенә алмаштырырга;

«Атмосфера һавасы» бүлекчәсенең беренче абзацында «пычранган булу» сүзләрен «пычрану» сүзенә алмаштырырга;

«Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү» бүлекчәсенең беренче абзацында «калдыкларның әйләнә-тирә мохиткә» сүзләреннән соң «, кеше гомеренә, сәламәтлегенә» сүзләрен өстәргә;

«Әйләнә-тирә мохит торышын мониторинглау системасын формалаштыру» бүлекчәсенең дүртенче абзацында «мониторинглау» сүзе алдына «атмосфера һавасын» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин